| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>422658, с. Большой Машляк, ул. Центральная, дом 20 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР МӘШЛӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>422658, Зур Мәшләк авылы, Үзәк урам, 20 нче йорт, |
| --- | --- |
| Тел.: (84361) 33613, факс: (84361) 33613 , e-mail:BmSl.Rs@tatar.ru | |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10.11.2025** **Зур Мәшләк авылы** **№ 48**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 21 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, көндез укучы студентлардан, бала вакыттан инвалид һәм 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре, һәр кешедән 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыйналган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга Сез ризамы?

– урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;

_ су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

_ торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

_ рөхсәтсез барлыкка китерелгән чүплекләрне юк итү.

«ЯКЛАП» «КАРШЫ»

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 13А йорты; Югары Мәшләк авылы, Нариманов урамы, 24а йорты; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50А йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге
Башлыгы М.М. Шәмсевәлиев